ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.03.2025 п.г.т.Алексеевское № 86

**2025 елга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында торак урынны карап торткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 маддәсенең 4 өлешенә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап торткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар,шулай ук үзгәрешләрнең чикле индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча» 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгына туры китереп

**карар бирәм:**

1. 2025 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләменең иң чик индексын расларга:

- шәһәр җирлеге күләме - 22,0 %,
- авыл җирлекләре күләме - 17,0 %.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**